КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 21 апрель г.Казань № 272

2018 елга Халык өстенлекләре
реестрын раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан Татарстан Республикасының норматив хокук актларын һәм муниципаль хокук актларын кабул иткәндә һәм тормышка ашырганда җәмәгатьчелек фикерен исәпкә алуны оештыру тәртибе турында» 2007 ел, 19 март, 90 нчы карарын үтәү йөзеннән һәм 2017 елда үткәрелгән социологик тикшеренүләр нәтиҗәләренә нигезләнеп, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән 2018 елга Халык өстенлекләре реестрын (алга таба – Реестр) расларга.

2. Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарына:

Реестрда күрсәтелгән халык өстенлекләрен тормышка ашыру буенча чараларны Татарстан Республикасының гамәлдәге һәм эшләнелүче дәүләт программаларына кертүне тәэмин итәргә, шулай ук әлеге чараларны тормышка ашыруны мониторинглауны контрольдә тоту буенча җаваплы затларны боерык белән билгеләргә;

2018 елның 1 декабреннән дә соңга калмыйча ачык өстенлектәге төп мәсьәләләр исемлеге ячтылыгында Реестрда күрсәтелгән ачык өстенлекләрне тормышка ашыру буенча үткәрелгән эш турындагы мәгълүматны «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә кертергә.

3. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәнфәгатьле органнары белән бергә Реестрда күрсәтелгән халык өстенлекләрен тормышка ашыру

буенча Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары эше барышын һәм нәтиҗәләрен массакүләм мәгълүмат чараларында даими яктыртуны тәэмин итәргә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасары Р.К.Нигъмәтуллинга йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 21 апрель, 272 нче
карары белән расланды

2018 елга Халык өстенлекләре реестры

| Т/с | Өстенлек исеме | Өстенлекне билгеләгән халык өлеше, процент | Социологик тикшеренүләр нәтиҗәләре буенча формалаштырылган төп проблемалар исемлеге |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Бәяләр һәм тарифлар үсүне тыеп тору, товарлар һәм хезмәт күрсәтүләрнең сыйфатын күтәрү | 60,5 | бәяләр һәм тарифлар үсү;<br>бәяләр һәм тарифларның икътисадый нигезсез булуы;<br>товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр бәяләренең аларның сыйфатына туры килмәве;<br>гомуми йорт ихтыяҗларына торак-коммуналь хезмәт күрсәтүләргә өстәп исәпләүләрнең югары булуы;<br>торак-коммуналь хезмәт күрсәтүләргә түләүләр формалаштыруның ачык булмавы;<br>торак-коммуналь хуҗалык предприятиеләре эшчәнлегенә дәүләт тарафыннан контроль булмау |
| 2. | Халыкның керемнәре дәрәҗәсен ктәрү | 53,5 | эш хакларының, пенсияләр һәм пособиеләрнең түбән дәрәҗәсе;<br>халык керемнәрен диспропорциональ бүлү |
| 3. | Ришвәтчелек һәм коррупциягә каршы тору | 42,0 | хакимият органнарында коррупцияне кисәтү буенча эшнең җитәрлек дәрәҗәдә нәтиҗәле булмавы;<br>гражданнарның түбән хокукый культурасы;<br>хокук саклау органнарына ышанычның түбән булуы;<br>ришвәтчелеккә җәза бирү системасының тиешле дәрәҗәдә каты булмавы |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
| --- | --- | --- | --- |
| 4. | Наркоманлыкка һәм эчкечелеккә каршы тору | 35,1 | алкогольне чиктән тыш күп куллану һәм наркотик чараларны медицинага ярашлы кулланмау нәтиҗәләре турында халыкның аз мәгълүматлы булуы;<br>алкогольнең халык өчен һәркем алырлык булуы;<br>наркотиклар китерү каналларын билгеләү һәм ябу эшенең нәтиҗәлеге тиешенчә булмау;<br>наркотик чаралар кулланган һәм тараткан өчен җәза бирү системасының тиешле дәрәҗәдә каты булмавы<br>эчкечелектән һәм наркоманиядән мәҗбүри дәвалау системасы булмау |
| 5. | Эшсезлек дәрәҗәсен киметү | 32,0 | югары хак түләнә торган эш урыннарының җитәрлек санда булмавы;<br>җитештерү үсеш алмау;<br>кече һәм урта эшмәкәрлек үсешенә хакимият органнарының игътибары җитмәү |
| 6. | Әйләнә-тирә мохит торышын яхшырту | 31,1 | гражданнарның түбән экологик культурасы<br>юлларда автомобильләр саны арту, аларның йортлар ишек алларында туплануы;<br>агым суларны сыйфатсыз чистарту;<br>предприятиеләрнең атмосфера һәм суга зарарлы калдыклар чыгаруы;<br>шәһәр (поселок) территориясендә экологик зарарлы җитештерүләр булу;<br>урамнарда чүп савытларының җитәрлек булмавы;<br>урамнарда чүпне сыйфатлы җыймау |
| 7. | Торакның һәркем алырлык булуын тәэмин итү | 21,8 | урта һәм түбән керемле гаиләләр өчен торак сатып алуны күздә тоткан программалар санының җитәрлек булмавы;<br>үсеш алмаган дәүләт торак төзелеше;<br>ипотека кредиты буенча югары процент ставкалары |